ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.08.2026 с.Старое Дрожжаное №365

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Түбән Чәке урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ Һади Атласи (Мөхәммәдхади Мифтахетдин улы Атласов) исемен бирү турында

Түбән Чәке авылыннан чыккан якташыбыз, танылган тарихчы-галим, күренекле җәмәгать һәм дин эшлеклесе, талантлы педагог-мәгърифәтче Һади Атласи (Мөхәммәдхәди Мифтахетдин улы Атласов) истәлеген мәңгеләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2017 елның 31 гыйнварындагы 14/2 номерлы «Муниципаль предприятиеләргә, учреждениеләргә (оешмаларга) исемнәр бирү, аларның исемнәрен үзгәртү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы күренекле гражданнар, оешмалар һәм тарихи вакыйгалар истәлеген мәңгеләштерү турындагы материалларны карау комиссиясе утырышының 2026 елның 11 августындагы 3 номерлы беркетмәсенә таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Түбән Чәке урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә Һади Атласи (Мөхәммәдхади Мифтахетдин улы Атласов) исемен бирергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы «Түбән Чәке урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (алга таба учреждение дип атала) директорына (Шиһабутдинова А.Р.):

2.1. учреждениенең исемен үзгәртү турында учреждение хезмәткәрләренең хезмәт кенәгәләренә язма кертергә;

2.2. учреждениенең локаль хокукый актларын әлеге карарга туры китерергә;

2.3. билгеләнгән тәртиптә, Учреждение исеме үзгәрүгә бәйле рәвештә учреждение уставына үзгәрешләрне әзерләргә һәм гамәлгә куючыга раслауга тапшырырга;

2.4. Уставка үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алуны һәм салым органында исәпкә кую турында яңа таныклыклар алуны, шулай ук учреждение исеме үзгәрүгә бәйле рәвештә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне һәм дәүләт аккредитациясе турында таныклыкны (кирәк булганда) яңадан рәсмиләштерүне тәэмин итәргә;

2.5. тиешле органнарга һәм оешмаларга (шул исәптән мәгариф бүлегенә, ЗАГС бүлегенә, Пенсия фондына, социаль иминият фонды һәм башкалар) учреждениенең исемен законнарда билгеләнгән срокларда үзгәртү турында хәбәр итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.Ф. Заляловка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.Р. Баһаветдинов